**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Иске Маврин авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 10** **22.09.2020**

**«2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» 2019 елның 10 декабрендәге 171 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты турында» 2019 елның 10 декабрендәге 171 номерлы Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы карарына (2020 елның 18 мартындагы 176 номерлы, 2020 елның 29 майдагы 179 номерлы, 2020 елның 29 июлындагы 185 номерлы карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 1 статьяның 1 пунктында:
а) 1 өлештә «10071,1» санын «10111,8» санына алмаштырырга;
б) 2 өлештә «10290,7» санын «10331,4» санына алмаштырырга;
в) 3 өлештә «219,6» саны.
1.2. «2020 елга Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1нче кушымтасының 1нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;
1.3. «2020 елга Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре» 2нче кушымтасының 1нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;
1.4. «2020 елга Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 5нче кушымтасының 1нче

таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге kарарга 3нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.5. «Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2020 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 6нчы кушымтасының 1нче таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 4нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә

2. Карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г. Нургалеев**